**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының 10 сыйныфында укучылар өчен олимпиада сораулары**

Үткәрү вакыты 120 мин.

## I бүлек

| Бирелгән сорауларга дөрес җавапларны күрсәтегез |
|---|

1. **Болгар чорында иҗат иткән язучы:**

а) Кол Гали ә) Сәйф Сараи
б) Фатих Кәрими в) Мәүлә Колый

**2. Ничәнче елдан болгарларда, рәсми рәвештә, ислам дине гамәлгә кертелә:**

а) 737
б) 922
в) 911

**3. Ислам дине белән бергә төркиләргә үтеп кергән һәм иң озак кулланышта булган графика:**

а) гарәп графикасы
ә) уйгур графикасы
б) рун алфавиты

## II бүлек

| Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез |
|---|

Идел-йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Идегәй әйткән көн килде.
Чыңгызның куйган хан тагы
Кан тагы булып әверелде;
Хан сарае камалды.
Кырым, Казан, Аҗдаркан
Башлы-башлы ил булды,
Алтын Урда таралды.

1. Әсәрнең исемен һәм жанрын күрсәтегез.
2. Төп геройларны санап чыгыгыз
3. Әсәр турында белгәннәрегезне языгыз.

______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________

## III бүлек

**Г.Исхакый иҗатына бәйле сорау-биремнәргә җавап бирегез**

1. Г.Исхакыйның “Ул әле өйләнмәгән иде” повестендагы Анна Васильевнага характеристика бирегез.

2. Повесть герое Шәмсинең эчке каршылыгы нидән гыйбарәт?

3. “Ул әле өйләнмәгән иде” повестеның яңалыгын нидә? Ничек уйлыйсыз, әсәр бүген дә заманча яңгырашлымы?

## IV бүлек

| IV бүлек биремнәренә җавап языгыз |
| --- |

“Тәрбия кыйлмак вә тәрбия итмәк дигән сүз фәкать ашатып-эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, бәлки ашатып-эчертеп үстермәк, вә баланың холкын, фигылен ислах кыйлмак вә төзәтмәк, вә, хайванидан чыгарып, инсаният чыгарып, инсаният дәрәҗәсенә китермәк, вә тәгълим бирмәк, вә үгрәтмәк, вә укытмак, вә әдәп нигезе бирмәк мәгънәсендәдер. Ошбу китабта зикер кыйлыначак хикәятләр, вәгазьләр вә нәсихәтләр һәммәсе, вә бу рисаләнең һәрбер кәлимәсе − бер тәрбиядер, шул җәһәттән “...........” дип ат бирдек.

1. Хезмәтнең исемен, авторын языгыз___________________________

_____________________________________________________________________
2. Ни өчен бу авторны “мәгърифәтче галим” дип атыйбыз. Аңлатыгыз.

_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

3. “Тәрбия”, “белем” төшенчәләрен кулланып, троплар, стилистик чаралардан да файдаланып, кыска инша языгыз.

_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________